# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**04 декабрь 2021 ел** **№2**

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Беренче Май бистәсе торак пунктында Средняя һәм Верхняя урамнарында асфальт-бетон өслекле юллардагы чокырларны ямау (килешү буенча сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы А.И.Закиров